ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» июня 2021 ел №176

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңавыл җирлегендәге муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе булган Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыруны туктату турында**

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы үтенечнамәсен карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңавыл җирлегендәге муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе булган Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кимүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 апрелендәге 103 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңавыл җирлегендәге муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе булган Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыруны тукталган дип кабул итергә.
2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына әлеге карар буенча оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.
3. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 октябрендәге 458 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең штат саны турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең штат саны» 2 нче кушымтаның 14 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төшереп калдырырга:
0,5 штат берәмлегендә «тәрбияче»;
0,5 штат берәмлегендә «кече тәрбияче»;
0,25 штат берәмлегендә «кер юу буенча машинист»;
0,25 штат берәмлегендә «пешекче».

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**